СӘЙ ГОМЕРЕҢ, СӘЙ ХАЛЫКЫҢ, СӘЙ ХАЛЫКЫҢ ДӘҢЬЯСЫ!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

10 декабрь, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 139 (8151) | Бәясе билгеләнгәнчә

ЧУВАШ БАСМАЛАРЫ ПРОБЛЕМАЛАРЫ КАРАЛДЫ

Узган атнада Казанда ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан республикада чуваш телендә нәшер ителә торган газета-журналларның кадрлар, методик, материаль-техник базасы үсеше белән бәйле проблемаларны киң тикшерү максатында семинар үтте. Семинарны мәгълүмат һәм матбугат министры И.Г.Әхмәтҗанов алып барды, анда министрлыкның әйдәп баручы белгечләре, ТР Президенты аппараты, Дәүләт Советы хезмәткәрләре катнаштылар. Семинарга Аксубай, Буа, Октябрь, Чүпрәле район газеталарының чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары, әлеге районнарның хакимият башлыклары урынбасарлары, «Сувар» республика чуваш газетасы редакциясе җаваплы хезмәткәрләре, республика Дәүләт теле-радиокомпаниясенең чуваш телендә эшләүче журналистлары чакырылган иделәр. Семинарда катнашучылар газеталар эшчәнлегенең нәшрият-агарту аспектларына тукталып, Татарстанда яшәүче чуваш халкының рухи тормышында милли матбугатның мөһим роль уйнавын ассызыкладылар. Чуваш теле белгечләре әзерләү проблемаларына кагылып, катнашучылар КДУның филология факультетындагы чуваш бүлеген ябуга юл куймаска кирәклеген басым ясап әйттеләр. Шунда ук урыннарда әлеге бүлекчә милли мәктәпләрне тәмамлаучыларны әзерләү эшен көчәйтергә кирәклеге күтәрелде.

Семинарда чуваш язмасына нигез салучы, беренче чуваш әлифбасы авторы И.Я.Яковлевның тууына 150 ел тулуны билгеләп үтәргә әзерлек мәсьәләләре турында да сүз булды.

Семинар Татарстанда чуваш мәдәнияты көннәре барганда үткәрелү сәбәпле, анда катнашучылар Г.Камал исемендәге театрда К.Иванов исемендәге чуваш Дәүләт Академия театры пьесасын карый алдылар.

Т.БУРАЙКИНА,
"Дуслык" газетасының чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасары вазифаларын башкаручы.

Инвалидлар декадасы кысаларында

Безне кайгырталар

Шикәр заводы ашханәсендәге ачык ишектән агылган көй ераклларга тарала.

Бүгенге кунаклар - заводның элеккеге һәм хәзерге эшчеләре: бездә очрашу, аралашу, үткәннәрне искә алу һәм киләчәк турында сөйләшү кичәсе.

Инвалидлар - исәнлеккә тилмергән кешеләр. Берәүләр тормышның ахыры җитте дип күңел төшенкелегенә биреләләр, тормыш белән кызыксынуларын югалталар. Әгәр яңашәдә дусларың, үзең эшләгән коллектив икән, аларның ярдәмен тою сиңа көч - куәт өсти.

Бу очрашу шундый изге нияттән оештырылган иде. Өстәлдә бай сый - нигъмәт, кунаклар да, хуҗалар да матур итеп киенгәннәр. Кунаклар йөзенә карап аларның ни кичергәнен аңлау кыен түгел иде. Озак аерылышып торганнан соң бу кешеләр күптәнге туганнарын очраткандай бер берләренең хәлен белергә ашыктылар: «Хәлегез ничек? Исәнлегегез ничек?»

Инвалидлар арасында төрле милләт кешеләре бар: А.И.Тимонин, Н.И.Аринин, Х.Х.Әхмәтшин, П.Д.Большаков, П.Н.Фролов, әфганлы В.Г.Хөсниев. Биредә заводның башка хезмәткәрләре дә бар: А.А.Мокеева, Д.М.Дәүләтшина, В.П.Озингина, Х.А.Сафиуллова, Н.Ф.Крылосова һәм башкалар. Алар заводка хезмәткә күп көчләрен биргәннәр, хәзер исә завод үзе аларны ярдәмнән ташламый.

Кунаклар күңелле җырлар тыңладылар, яңа иттеләр. Алар өчен «Ветеран» ансамбле, бакча хезмәткәрләре, яшьләр, солистка лар Т.Е.Иванова, Р.Х.Бакирова, М.М.Маткушкина чыгыш ясадылар. Инвалидлар завод житәкчелегенә күптән түгел шикәр комы таратып чыгулары өчен дә рәхмәтләрен белдерделәр.

Алар таралырга ашыкмадылар, чөнки бәлә иделәр: завод автобусы аларны өйләренә тиклем озатачак.

Һәм шулай булды да.

Л.ТАФЕЕВА.

Илдә ниләр бар икән?

ФАҖИГА

Кемерово өлкәсенең «Зыряновская» шахтасында булган каты шартлау 67 кешенең гомерен өзде (Бу әле төгәл мәгълүмат түгел). Юкса, күмер комбайннарын эшләтә башлау алдыннан җыелып торган газлар бармы - юкмы икәнлегә дә тикшерелгән булган. Әлегә хәбәрне Швециягә барышлый ишеткән Русия президенты бу шартлауны «стихия» дип атады. Әмма «стихияле» бәла - каза планлы рәвештә артырга тиеш түгелдер бит. Узган ел, мәсәлән, чыгарылган һәр миллион тонна күмергә... бер шахтер гомере туры килгән. Быел әлегә «миллион» ике гомер сорый башлаган. Димәк, эш техник җиһазларның, куркынычсызлыкны тәэмин итә торган шартларның камил булмавында дигән нәтиҗә чыгарырга була.

Кемерово губернаторы Аман Тулиев әлегә зур фаҗига уңаеннан матәм көне игълан итте. Узган җомга көн бөтен Россия Федерациясе буенча да матәм көне игълан ителде.

Р.СОЛТАНОВ.

Тырышлык тыныгы белмәс

Кизләү фермасына төшке савым чорында барып чыктык - сөте ишле сыерларны монда көнгә өч тапкыр савалар. Килгән - килгән бозаулату бүлегенә керми китә күрмәгез, дип киңәш иттеләр. Һәм анысы юкка түгел икән - биредә эшләүчеләрнең үз хезмәтләрен ничек күңел биреп башкаруларын да, моның уңай нәтиҗә бирүен дә, кем әйтмешли, сукыр күз белән дә күрерлек. Хезмәт шартлары әллә ни мактанырлык булмаса да, технология таләпләрен җиренә җиткереп алдыралар биредәгеләр. Ә инде буаз сыерларны ничек карау, бозаулаганнарына һәм яшь үрчемгә нинди игътибар кирәклеген монда эшләүчеләргә әйрәтеп торасы юк. Әйтик, гомере буе диярлек шушында тырышып хезмәт куючы Сания апа Кәримованы тегеләй эшлә, болай ит, дип әйрәтеп торырга кемнең теле әйләнсен ди инде?! Гомерендә күпме яшь малга кендек әбисе булган, күпмесен карап аякка бастырган терлекче бу эшнең рәтен белми димени. Кайсы сыерның бозавы нинди хәлдә туганлыгын да, кайсы бозауның сөткә, башка азыкка ничек ияләшүен дә, кыскасы, малларының һәркайсы турында вагы - төягенә кадәр белеп тора бит ул. Ә ел саен өч йөздән күбрәк бозау уза аның кулы аркылы. Җәй көне, малларны лагерьга күчергәч башка савучыларның хезмәте бераз жиңеләя төшкән чакларда да бозаулату бүлегендә эшләүченең мәшәкате шул ук кала. Менә хәзер, кышкы чорда да, башка савучылар үпкәләмәстер дип уйлый бызы, бу бүлектәгеләрнең эше артыгы белән четерекле. Кайчандыр кулланылышта булып та, соңрак онытылган һәм инде икенче ел яңадан гамәлгә кергән салкын ысул үзе генә дә бозау караучыга күпме өстәмә мәшәкать тудыра. Ул кышкы читлекләрне көнгә ничә мәртәбә ачып, бозауларның берсенә дә җил -мазар үтәрлек булмасын өчен яңабаштан салам белән томалап чыгарга туры килә Сания апага. Хезмәтенең авыр булуын яшермәсә дә, зарланып әйтүе түгел. Мәшәкате күбрәк булса да, бозауларның исән - имин үсүенә канәгать ул. Ә салкында асрауга күчергәч яшь үрчемнең сакланышы күзгә күренеп яхшырды, үлем - китем юк дәрәҗәсендә, артым югары.

... Сания апа бозауларын карап бетерешкә абзар яныннан җигүле атында ире Дамир абый килеп туктады. Күрше абзарда гына савым сыерлар группасына хезмәт күрсәтә икән ул. Әнә шулай бер йорттан икәүләп йөриләр алар фермага. Кәримовларның уллары Тәһир да шушы ук хуҗалыкта эшли - столярлык мастерскоенда. Хезмәт белән көн күреп ятулары. Әле шушы арада гына хуҗалык хезмәт хакы буенча барлык бурычларын да каплаган. Тырышып эшләгәннәр акчасын да мулдан алган. Ә Кәримовлар шундыйлар исәбендә.

Р.МУЛЛИН.

Рәсемдә: «Киекле» хуҗалыгы бозау караучысы С. Кәримова.
Н.АЗИЗОВ фотосы.

Дәеклы ялга китсә дә...

«Гомер буе эшләп бер - сәламәт кылыш пенсия яшенә житә кеше өчен зур бәхет дип саныйм мин», ди «Татарстан» КХАсы терлекчесе Фәүзия апа Хәрләмова. Әмма миңа пенсия китерделәр дип бер дә өйдә утырасы килми әле аның. Бүген дә ул үз хезмәт постында. Кешеләр татлы йокыдан уянмаган бер вакытта ул җитез адымнар белән фермага ашыга. Монда аны маллары көтә, бераздан бина эче күңелле сөйләшүләргә, чиләк чыңнарына күмелә, яңа сауган сөтнең хуш исе тарала. Хезмәт иртәсе шулай башлана. Фәүзия апага боларның һәммәсе дә таныш, һәммәсе дә якын шул. Шулай булмый ни, 30 ел гомер узган бит инде. Ул эшен намус белән башкаруын дәвам итә. Җәй буе аның группасы алдынгылар сафында булды. Хуҗалыкның гомуми җыелышында савучылар арасында икенче урында булганы өчен кыр ягы тарафыннан акчалата премия белән бүләкләнде. Әйтергә кирәк, тырыш хезмәт нәтиҗәсе бу. Әйе, гомер буе булсынга хезмәт куйды ул. Алай гына да түгел, яшьләргә үрнәк булырлык итеп эшләде. Янында савучы һөнәрен өйрәнеп үскән кызы Эльмира да каникул вакытларында сыерлар сауды. Әлегә 11 нче сыйныфта укый әле ул. Нәкъ менә сыерлар сауган өчен ул мәктәп дирекциясе тарафыннан кул сәгате белән бүләкләнде дә инде. Без ялсыз - бәйрәмсез тармакта тырышып хезмәт куючы Фәүзия апа Хәрләмованың акыллы киңәшен тоеп яшибез. Ә хезмәт ветеранының безнең арада булуы үзе бер шатлык ул.

З.ИСМӘГЫЙЛЕВА,
савучы.

Хөрмәтле дуслар!

1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу төгәлләнеп килә. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.



Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.

Түгәрәк өстәл

СПИД Норматка килеп җитәрме?

Районыбызда яшәүчеләрнең байтаклары өчен бу сорау урынсыз тоела. Бүген без шул дәрәҗәдә оптимист була алабызмы?

- СПИД, СПИД... Безнең провинциягә килеп җитми бит ул, - безнең күптәнге укучыларыбызның берсе әңгәмә вакытында шулай диде.

Рәсми мәгълуматлар буенча Татарстанда ВИЧ инфекцияле кешеләр саны өч дистәләп исәпләнә. Алар башкалабыздагына түгел, Яр Чаллы, Әлмәт, Алабуга шәһәрендә дә теркәлгән. Әлеге әңгәмәдәшебез шулай фикер йөртә икән, башкаларның бу авыруга мөнәсәбәте ничек булуын чамалавы кыен түгел. СПИДны безнең җирле җитди проблемабызга әйләнгәнче шулай кабул итәрбезме икән без.

Октябрь районы үзәк шифаханәсе стеналарында үткән түгәрәк өстәл артында әңгәмә (бүген аны сезнең игътибарга тәкъдим итәбез) Бөтендөнья СПИД белән көрәш көненә багышланган иде. Анда район үзәк шифаханәсенең эпидемиология мәсьәләләре буенча баш табиб урынбасары Дилүсә Кадыйровна Әндәрова, дерматовенерология табибы Наталья Степановна Шикова, табиб - нарколог Семен Ильич Федотов, гаиләне планлаштыру кабинеты табибы Лилия Әбдрәшитовна Даутова, район хакимиятенең яшьләр һәм балалар эшләре буенча бүлек мөдире Раилә Йосыфхановна Хәниева, район эчке эшләр бүлегенең җинаять эзләү бүлеге начальнигы Виктор Александрович Сиднев, район мәгариф бүлегенең тәрбия эшләре буенча методисты Гүзәл Дамировна Әһлиуллина катнаштылар.

Д.К.ӘНДӘРОВА:

- «Балалар СПИД булган дөньяда яшиләр»- быел Халыкара СПИД белән көрәшү көне шундый девиз астында үтә. Рәсәйдә һәм Татарстанда бу авыру наркоманнардан башланды. Ул географик чикләрне киңәйтеп даими үсеш ала. Медицина көче белән генә бу бәладан котылу мөмкин түгел. Бу хәлдә җәмәгатьчелек, педагоглар, тәрбиячеләр, яшьләр оешмалары һәм берләшмәләре, ата - аналар, гомумән, бу хәлнең җитдилеге турында уйлаучылар битараф булырга мөмкиннәрме?

С.И.ФЕДОТОВ:

- Бу авыруга җиңел карашны бетерергә кирәк. Монда принциплар спиртлы эчемлекләр, наркотикларга мөнәсәбәт кебек үк. Әмма тигезләмәнең ничек үзгәрүен карагыз: әгәр дә өч - дүрт ел элек хәл бер төрле үк булса, хәзер спиртлы эчемлекләр кулланганнары өчен учетта торучы яшүсмерләр саны кискен артты. Хәтта транквилизаторлар белән мавыгучы 12 яшьлек кыз да бар... Һәм, шунысы кызганыч, беркем дә читләр хатасыннан гыйбрәт алмый - һәркем үз тәҗрибәсен булдырасы килә. Мәктәпләрдә алкогольгә каршы пропаганда буенча занятиеләрне ай саен үткәрергә кирәк дип саныйм. Шәхсән үзем атна саен бер - ике сәгатемне шуңа бүлә алыр идем.

Наркология бүлегенең материаль - техник базасына килгәндә, ул сизелерлек яхшыртуны таләп итә. Бу җәһәттән, махсус программа бар, әмма аны финанслау буенча гамәли адымнар бөтенләй ясалмады әле.

В.А.СИДНЕВ:

- Наркотик матдәләр кулланучы яшүсмерләрнең саны арту борчу тудыра. Гашиш, әфьюн, мәк саламы, киндер кулланыла. «Энәдә» утыручылар да бар. Җинаятьләрдә катнашкан яшүсмерләрнең байтагы исерек яисә наркотик матдә кулланган хәлдә була. Бу безнең барыбызны да бик борчый. Бездә учетта барлыгы 46 наркоман тора. Ә яшерен эш йөртүчеләр күпме тагын. Күрсәткечләр үсә. ВИЧ - инфекция тарату, наркотик матдәләр сату һәм саклау өчен Россия Федерациясе җинаять кодексында аерым маддәләр каралган.

Н.С.ШИКОВА:

- Районда сифилис инфекциясе дәвам итә. Нигездә тәртипсез сексуаль тормыш алып баручылардан йога ул. Сифилис белән авыручылар арасында 7 кеше - балигъ булмаганнар. Сүз уңаенда шуны да әйтәсе килә, ни өчендер кешеләр иммунитет барлыкка килмәвен истә тотарга тырышмыйлар - икенче төрле итеп әйткәндә, икенче, шулай ук өченче тапкыр да авырырга мөмкин.

Венерик авырулар гомуммедицина гына түгел, социаль проблема да. Бу планда җитмешенче - сиксәненче елларда җәмәгатьчелек, хезмәт коллективлары, идарә органнары белән зур эш алып барыла иде. Аның нәтиҗәсе дә булды. Бүген исә хәл бөтенләй башкача. Без барыбер тик үз көчебезгә генә таянабыз. Авыруларны эзләү буенча да зур катлаулыклар туа. Аноним тикшерү мәсьәләсен хәл итү буенча да эшлибез.

Л.Ә.ДАУТОВА:

- Без, гинекологларны, генофонд борчый - венерик авырулар, наркомания арта, эчүчелек чәчәк ата, СПИД килә, ә анасы сәламәт булмаганда, аңардан нинди бала туа? Балалар үлеме анализы күрсәткәнчә, аңа нәкъ менә җенси юл белән күчүче авырулар сәбәп була.

Балаларның билгеле бер проценты җәнесләр патологиясе белән дөньяга килә - рак яшәрә, бездә 8 айлык рак авырулы кыз бала да бар хәтта. Абортлар саны арта - без күпләрне узып киттек. Әмма бит алар ахыр чиктә кысырлыкка китерә. Бүген бездә 56 баласыз пар бар.

Хәзер поликлиника каршында гаиләне планлаштыру хезмәте эшли. Без үзебезнең кабинетыбыз кешегә кирәк булсын өчен зур тырышлык куябыз. Бу кабинетка мәктәптә укучы кызларның да килүен телибез. Килешегез, өлкәннәр киңәшләре һәм аларның тыюлары бу ситуациядә зур нәрсәгә ия түгел - яшүсмерләр элеккегечә үк җенси тормыш белән яшиләр. Безнең бушлай йөклелектән саклану средстволарыбыз бар, бер дигән видеокассеталарыбыз да шуңа хезмәт итә. Аларны педагогларга да үз эшләрендә файдаланырга киңәш итәр идек. 1997 нче елда бездә балигъ булмаганнарның бала төшерү факты теркәлмәде. Ә менә элеккеге елны ул бар иде. Табиблар яңа өлгереп килүче Яшьләр йорты мөмкинлекләренә зур өмет багълыйлар - без андый яшүсмерләр өчен медицина консультацияләре, системалы занятиеләр үткәрә алыр идек. Бу бик кирәк. Бездә тикшерү үткән 552 кызның 180ендә авыру табылды. Ә булачак ананың сәламәтлеге бик мөһим.

Залдан тавыш: - Гинекологлар шәһәрнең өченче мәктәбендә медицина каравы үткәрделәр - ата - аналар, балалар исеменнән рәхмәт аларга. Авыруны дәвалауга караганда кисәтү җиңелрәк. Балигъ булмаган яшүсмер кызларны кабул итү өчен кабинетны хатын - кызлар консультациясендә түгел, ә балалар консультациясендә ачасы иде.

Р.Ю.ХӘНИЕВА:

- Безнең бүлек республикада ышаныч телефоны ачу буенча күрсәтмәләр алды. Юрист, психолог, нарколог, сексопатологны үз эченә алган мондый хезмәт башка шәһәрләрдә уңышлы эшли. Залда өлкән класс укучылары утыра - безгә мондый хезмәт кирәкме? Бу сорауга җавапны безгә махсус анкеталаштыру да бирер бәлки.

Г.Д.ӘҺЛИУЛЛИНА:

- Гаиләне планлаштыру кабинеты уңаеннан шуны өстисем килә, регистратураны да аерым ясарга кирәк - күпләр кыек карашлардан һәм кирәк булмаган сораулардан шикләнәләр. С.И.Федотов инициативасы урынлы - без аны хуплыйбыз. Җенси гигиена факультеты ачу зарури. Тик менә авылларда катлаулырак - анда белгечләр юк.

Д.К.ӘНДӘРОВА:

- Бүген без үзара аңлашуга ирештек дип уйлыйм. СПИД безнең якка актив килә һәм корбан рәвешендә нигездә балалар кала, ни өчен дигәндә күпчелек очракта нәкъ менә ана авыру йоктыру чыганагы булып тора. Кызганычка каршы, бу куркыныч авыруга каршы әлегәчә дарулар юк.

***

... АКШта һәм кайбер башка алга киткән илләрдә ВИЧ - инфекцияле кешеләр гомерне озынайтырга мөмкинлек бирүче катнаш дәва алалар. Өч ел дәвамында авыру төнлә һәм көндез зур дозада таблеткалар кабул итә. Тулы дәвалау курсының бәясе якынча 35 мең доллар тора. Шуңа төрле өстәмә тикшерүләр өчен дә түлисе була (СПИД белән көрәшү һәм профилактика буенча Россия үзәге мәгълуматларыннан) Татарстанда исә әлегәчә җенси юл белән наркоманнан авыру йоктырган бары бер (!) кызны дәвалау өчен генә акча бүленгән. Ул бары тик өч айга гына житәчәк...

Әңгәмәне газета өчен Т.НАЗАРОВА әзерләде.

Тормыш дәвам итә

Көз көне республикада халыкара сукырлар көненә багышланган декада узды. Шулай килеп чыкты: безнең газета бу чара турында яза алмады. Юкса, күрмәүчеләрнең проблемалары баштан ашкан. Шул ук вакытта быел безнең районда беренче тапкыр Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте Татарстан Республика идарәсе рәисе Владимир Алексеевич Федорин булып китте. Бу кеше турында очрашудан язмалар блокнотта сакланган, тәэсирләр хәтердә калган һәм алар - бик якты. Ул чакта район мәдәният йортында җәмәгатьчелек Октябрь территориаль башлангыч оешмасын - 45 һәм аның җитәкчесе Ф.Н.Хаҗиморатовны 75 яше белән котларга җыелган иде. Күпләр чыгыш ясадылар, җылы сүзләр сөйләделәр, трибунага Владимир Алексеевич та чыкты. Аның чыгышы төгәллеге, образлылыгы, ачыклыгы белән аерылып тора иде. Мин аның интеллигентлыгына, гадилегенә хәйран калдым. Кыска әңгәмәбез вакытында ул сорауларга дулкынланып җавап бирде, әмма эш турында кызыксынып сөйләде.

- Владимир Алексеевич, оешмагыз турында кирәк тукталсагыз иде.

- Республикабызда 16 территориаль оешма, сезнең Октябрь районара башлангыч оешмасы бик әйбәт эшли.

- Учетта күпме күрмәүче тора?

- Алты мең ярым, ә җәмгыять членнары меңгә азрак. Без оешмага 18 яшьтән узганнарны алабыз.

- Күрмәүчеләрнең иң катлаулы проблемасын атасагыз иде.

- Бу - инвалидларның иҗтимагый файдалы хезмәттә катнашуы. Күрмәүчеләр 200гә кадәр һөнәр буенча эшли алалар. Әмма хәзер дәүләт заказы алу кыен. Татарстанда бүген 5 укыту - производство кабинеты эшли: икесе - Казанда, Алабугада, Чистайда һәм Бөгелмәдә. Кыен булса да түзәбез. Хөкүмәт ярдәменә, Президент хуплавына ышанабыз. Оешмабызны дәүләт яклавына махсус программа бар.

- Күрү сәләтен югалткан кешеләргә нәрсә әйтер идегез?

- Төшенкелеккә бирелмәгез. Тормыш дәвам итә.

Владимир Алексеевичның хатыны, республика социаль реабилитация һәм сукырларны һәм аз күрүчеләрне профессиональ әзерлек үзәге методисты Наилә Исламовна озата килгән иде. Соңрак без Федоринның мәктәп яшеннән күрү сәләтен югалтуын белдек. Һөнәре буенча ул укытучы, ә идарә рәисе итеп ике ел элек сайланган.

Т.НАЗАРОВА.

Таныш булыгыз: рәсемдәгә мәлаем йөзлә бу кыз шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы сыер савучысы Надежда Хмелева. Бик уңган, тәртипле, ипле кеше ул. Тырышлыгы да сокланырлык. Шуңа да быел сыер савучыларның район конкурсына вәкил җибәрергә кирәк булгач, җитәкчеләр Хмелева фамилиясенә тукталдылар. Кыз аларның ышанычын аклады: яшь савучылар конкурсында икенче булды Надя.

Надежда хәзер дә сынатмый: аның һәр сыердан савылган сөт күрсәткече иң яхшы нәтиҗәләрнең берсе.

Н.КВАШНИНА фотосы.

Бикүле фермасы: ромашкалы, гөлле, чыршылы...

Ап - ак итеп агартылган стеналар, яңа гына известь пумаласы үткәнлеге күренеп торучы читлекләр кырыена беркетелгән яшел нарат ботаклары, чип - чиста идәннәр. Ә һавасы... Җиңел ачыла торган зур ишектән килеп керүгә үк сизелә аның корылыгы, борынга исә ылыс исе килеп бәрелә. Чиста салам өстендә аналарын имеп ятучы дуңгыз балаларының һәркайсын кулга алып сөясе килә хәтта: алсу төстә дә, чип - чисталар үзләре... Газета укучы боларның барысын да телевизордан чыккан сурәт итеп күз алдына китергәндер яисә мәртәбәле семинар көтүче берәр хуҗалыкны тасвирлый дип уйлыйдыр, мөгаен. Бикүледәге... дуңгыз фермасы турында бара сүз. Әйе, татарлар дуңгызлар карарга өйрәнделәр бит. Әле ничек кенә! Шифалы дару үләннәренә кадәр хәзерләгәннәр бит биредә. Читлекләр буйлап тартылган җепкә эленгән үләннәр арасында нинди генә юк: ромашка, кычыткан... Шул үләннәрдән төнәтмә ясап, малларга эчертмәгән көннәре сирәк терлекчеләрнең. Махсус чаннарда үлән суы торгангамы, фермага гына хас үзенчәлекле ис тә сизелми биредә. Көзен хәзерләп калдырылган кәзне ал тагын... Бик яраталар аны дуңгызлар.

Гомумән, малларны ашатуга зур игътибар бирелә Бикүледә. Терлекче егетләр азык хәзерләнә торган чаннарны бер дә суытмыйлар. Иртә белән ботка пешерсәләр, әбәткә бәрәңге ясыйлар. Кичкә тагын берәр нәрсә. Күмер, акбур, тоз ише әйберләр дә алларыннан өзелми. Яшь, энергияле Рәстәм Шәйхетдинов мөдир дә үзе, ветеринария табибы да. Маллар үсешенә тәэсир итәрлек бер генә ветеринария таләбен дә үтәми калмый. Шуңадырмы, маллар исән - имин, тиз үсә биредә. Хәер, ашату яхшы, аслары коры, җылылык җитәрлек булганда тәгәрәшеп үсә ул мыркылдыклар. Биредә дә бит ел башыннан ноябрьгәчә 1324 баш яшь үрчем алынды. Декабрьдә тагын 250ләп баш дуңгыз баласы туар дип көтелә фермада. Һәр 100 төп анага 3908 баш туры киләчәк.

Билгеле инде, Бикүледә дуңгызлар өчен мондый шартлар үзеннән - үзе тумаган. Күңел биреп, шушы мыркылдыкларга тиз дә, исән - имин килеш үстерү өчен җан җылысын да кушып эшләүче терлекчеләр тырышлыгы бит бу. Мөдир таләп итә, калганнар үти. Шулай булмаса, 10 көн аралаш читлекләрне агартып, 3 көнгә бер идәнне известлап торырлар идемени?! Агалы - энеле Илфак һәм Исхак Хәйруллиннар, Миншакир Сафиуллин, Хәмит Әһлиуллин, Сабир Габитов, Хәниф Батдалов һәм Хасыйбулла Сәгыйров ферманы үзләренең икенче өйләредәй күреп, көн - төн эш урынында булалар. Шулай итмәсәләр, дуңгызлары тәүлек саен уртача 350 - 400 грамм артым бирмәсләр иде. Хуҗалыкның дәүләткә ит сату буенча килешү йөкләмәсен срогыннан алда үтәве һәм озатылган барлык итнең 43 процентын дуңгыз ите алып торуы да шул хакта сөйли.

Гомумән, бикүлеләрнең ел азагын хезмәт нәтиҗәләре белән якынайтулары көнкүреш бүлмәсеннән үк күренеп тора: декабрьнең беренче декадасында ук биредә аллы - гөлле уенчыклар белән бизәлгән яшел чыршы тора иде. Стенага асылган гөл чүлмәкләреннән исә традисканциянең кучкыл яшел тәлгәшләре салынган. Бүлмә дә егетләр кулы белән бизәлгәнгә шундый ямьле, гөлләре исә аларның җан җылысы белән үстерелгәнгә шундый матурдыр, дигән нәтиҗәгә килдек без.

Р.ГИНЯЕВА.

Рәсемдә: Р.ШӘЙХЕТДИНОВ.

?Сорау-җавап

Торакка дөрес түлибезме?

Безнең йортыбыз бик иске, туэган, ул 50 нче елдар башында ук салынган. Шуңа карамастан, фатир өчен түләүдә безгә бермикадәр ташлама да каралмаган, айныкын-айга яңа йортларда яшәүчеләр кебек үк түләп барабыз. Бу дөрес-ме? Гомумән, фатир өчен түләү тәртипләре нинди?

М.Рәхимова.

Норлат шәһәре.

Без бу сорау белән район хакимиятенең сатып алучыларны яклау комитеты рәисе **Р.Суфияновка** мәрәҗәгать итеп торак йортларга, фатирларга түләү тәртипләре турында сөйләвен үтендек.

-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1994 елның декабрендә чыккан «Торакка түләү һәм торак биналарга техник хезмәт күрсәтү ставкаларының үзгәрүе турындагы» Карарына нигезләнеп «Торакка һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә дифференциацияле түләү турында» вакытлыча положение (1995 ел, 28 нче август) кабул ителә. Положениенең гомуми тәртибе түбәндәгечә.

Анда торак белән берләштән халыкка күрсәтелә торган коммуналь хезмәтләр өчен дә түләү тәртипләре билгеләнгән.

Кулланучы шундый түләүләрне алдагы айның 10сыннан дә соңга калмыйча гамәлгә ашырырга тиеш. Үзвакытында түләмәгән очракта тиешле вакыттан чыккан һәр көн өчен 0,1 процент күләмендә пеня түләтелә.

Кулланучы даими яши торган урыныннан бер айдан артык вакытка китеп торса, җылылык һәм фатир өчен түләүдән кала тиешле документ нигезендә башка хезмәтләргә түләү алынмый. Шулай, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләтелгән ставкалар буенча түләүче вакытлыча яши торган урынында да шундый ук льготалар белән файдалана. Икесендә дә бер үк вакытта льготалардан файдалану рәхсәт ителми.

Торак-коммуналь хезмәтләргә бәя (ставка, тариф) үзгәргән очракта квартал саен, шулай ук кулланучы гаризасы буенча ел азагында яңадан санау үткәрелә. Ставкаларны һәм тарифларны ТРның Министрлар Кабинеты раслый. Торак-коммуналь хуҗалыклары үзгәрешләр турында халыкка үзвакытында хәбәр итәргә тиешләр. Аерым категориядәге затларга коммуналь хезмәтләр һәм дәүләт коммуналь, җәмәгать тораклары өчен түләү өчен льготалар торак бүлмә мәйданының социаль нормасы чикләрендә саклана, ягъни изолированный фатирларда ул бер кешегә гомуми мәйданның 16,2 кв.м, һәм коммуналь фатирларда, кунакханә типындагы йортларда 12 кв.м дан чыгып исәпләнә.

Торак өчен түләү

Торакка түләү аның мәйданының берәмлегә амортизациясе исәбеннән торак фонды торгызу, яңартуга киткән түләүне дә үз эченә ала.

Торакка түләү ставкасы түбәндәге факторлар:

-ТР Министрлар Кабинеты билгеләгән гамәлдәге база ставкасы;

-таушалу дәрәҗәсе;

-шартлы комфортлылык дәрәҗәсе.

-төзәлеш тибы буенча билгеләнә.

Түләү ставкасы түбәндәге формула белән исәпләнә.

Сн=Сбаз.н х Пкв.м х Кжил.п

Биредә Сн- торакның конкрет 1 кв.м ына түләү өчен айлык ставка;

Сбаз.н.-1 кв.м торак өчен түләүгә база ставкасы (ТР Мин.Каб. карары буенча (1995 елның 4 нче декабре) ул 1000 сум);

Пкв.м- торакның гомуми мәйданы;

Гомуми мәйданга торак һәм ярдәмче бүлмәләр (кухня, коридор, ванна, туалет һәм башкалар) керә һәм алар торак йортны алып торучы һәркемгә тигез бүленә.

К.жил.п.-торакка түләү коэффициенты, ул түбәндәгечә ачыклана.

К.жил.п.= Э х (1-КИ)х УКхТС.

Биредә Э-этаж коэффициенты;

КИ-торакның фактик туэу коэффициенты, ул район хакимияте каршындагы техник инвентаризация бюросында билгеләнә;

УК-торак йортның шартлы комфортлылыгы төзәтмәле коэффициенты.

ТС-төзәлеш тибына төзәтмәле коэффициент.

Төзәтмәле коэффициентлар түбәндә күрсәтелә.

Торакка түләү коэффициенты торак йортның фактик туэу дәрәҗәсенә карап һәрвакыт яңадан исәпләнә. Хакимият башлыгы карары нигезендә өй нык туэган дип табылса торакка түләү алынмый.

Түбәндә торак өчен түләү ставкаларын исәпләгәндә кулланыла торган төзәтмәле коэффициентларның саны күрсәтелә:

Этаж (э)-беренче этаж-коэффициент 0,9, икенче һәм аннан югары-1,0, соңгысы-0,95.

Төзәлеш тибы (ТС)-кирпеч-1,00, панель, блок һәм монолит-0,95, агач һәм кирпеч-агач, җыелма-щитовой-0,90.

Шартлы комфортлылык дәрәҗәсе (УК).-изоляцияләнгән фатир-1,0, коммуналь фатирдагы бүлмә-0,8.

- Торак һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә дифференциацияле түләү турында» вакытлыча положение торакка базар бәясе белән түләгәнчегә кадәр гамәлдә булачак.

Котлыйбыз

Такта өстендә утлы көрәш

Ноябрь азагында нефтьчеләр каласы Әлмәттә ТР эчке эшләр министрлыгы дәүләт янгынга каршы службасының икенче отрядлары бүлекчәләре арасында шәхси команда беренчелегенә шахмат турниры үткәрелде. Барлыгы 20 команда һәм 40 кеше катнашты, шул исәптән 73 нче ВПЧ дан Саврандеев һәм Әһмәдиев та бар иде. Уен әйләнә системасында 10ар кешелек 4 группа арасында барды, ягъни катнашучы 9 партияне үтәргә тиеш иде. Һәр группада җиңүче ярымфиналга керде.

Г.Саврандеев өчен старт уңышлы килеп чыкты. Үз группасында ул беренчелекне, ә ярымфиналда икенче урынны алды. Бу көрәштә ул турнирга җитди һәм дөрес әзерлеген, тирән теоретик белемнәрен һәм сугышчан холкын күрсәтте. Шулай ук мораль-психологик һәм физик әзерлеккә нык игътибар бирелгән иде.

73нче ВПЧ командасы 3нче призлы урынны яулады.

А.Костин.

Норлат шәһәре.

Күңелле ял итегез!

Соңгы вакытларда районыбызда төрледән - төрле кызыклы мәдәни чаралар булып тора. Башка төбәкләрдән театр, эстрада коллективлары да еш килә башлады безгә. Кайбер артистларның килүе турында тамашачыларның шактые белмичә дә калгалый. Менә шуңа күрә дә моннан ары районда буласы мәдәни чаралар турында газетабызда шушы рубрика астында хәлдән килгәнчә алданрак хәбәр итеп торырга булдык.

Шушы максаттан беренчә әңгәмәбез - район мәдәнияти йорты директоры вазифаларын башкаручы К.Г.Зәбиров белән.

- Район мәдәнияти йортында бүген кич, 19 сәгатьтә халкыбызның яраткан җырчысы Әлфия Афзалова концерты буласы турында хәбәр иттек инде. Ә бу арада тагын нинди яңа тамашалар көтелә?

- Иртәгә, 11 декабрьдә Чистай татар халык театры артистлары килә. Моннан элек, театр декадасы кысаларында алар безнең тамашачыларны бик күңелле комедия һәм концерт күеп куандырып киткәннәр иде. Бу юлы Туфан Миңнуллинның «Гергери кияүләре» комедиясен алып киләләр. Әлә күптән түгел генә шушы спектакль белән алар Казан сәхнәсендә уңышлы чыгыш ясап кайттылар. Шуна күрә, иртәгә кичкә сигезенче яртыга район мәдәният йортына килүчеләргә үкенерлек булмас дип уйлыйм.

Киләсе атнада да бик күңелле мәдәни вакыйгалар көтелә. 16 декабрьдә Кама Аланы мәдәният үзәгенең «Чулман - су» дигән халык җыр һәм бию коллективы барлык милләт тамашачысының да күңеленә хуш килердәй программа тәкъдим итә. Концертта татар, рус, чуваш җырлары да, денья халыклары биюләре дә, юмор да күп булачак. Ансамбль район авылларында да чыгыш ясаячак һәм һәр авылда программасын анда кайсы милләт халыклары яшәвенә карап күрсәтергә җыена.

Әйкенче көнне, 17 декабрьдә район мәдәният йорты Норлатка беренче талкыр (!) килә торган цирк коллективына бирелә. Мәскәүдә Дуровның җәнлекләр циркы барлыгы турында моңарчы ишетеп кенә белгән яшь тамашачыларыбыз ул көнне күп төрле экзотик җәнлекләрне үз күзләре белән күрә алачаклар. Аю балалары да, крокодиллар, еланнар, маймыллар, этләр, песиләр... кыскасы, берсеннән берсе кызыклы җәнлекләр катнашында булачак ул цирк. Яшь тамашачылар аларны залда утырып кына карап калмыйча, яннарына килеп, тотып та карый алачаклар, кайсылары янында фоторәсемгә дә төшәргә мөмкин булачак. Моннан тыш, билетлар буенча лотерея уйнатылып, кызыклы отышлар да чыгачак.

Мөмкин кадәр күбрәк балалар килә алсын өчен ул көнне өч сеанс күела:

Кыскасы, бу ике атнада тамашачыларны шактый бай мәдәни программа көтә. Ә яңа тамашалар турында тагын хәбәр итәрбез әле.

Котлыйбыз!

Киекле авылында яшәүче **Хафиз Исмәгыйль улы һәм Җәүһәрия Хөснулла кызы Зәйнетдиновларның** 9 декабрьдә бергә тормыш коруларына 25 ел тула.

Әти, әни!
Һәлакәтләр сезне читләп үтсен,
Күңелләргә кайгы тулмасын.
Ходай сезгә озын гомер бирсен,
Шатлыкларның чиге булмасын.

Иңизге теләкләр белән балаларыгыз исеменнән кызыгыз Гөлия.

Норлат шәһәрендә яшәүче олы хөрмәткә лаек булган кадерле абыебыз **Харис Нурулла улы Атауллинга** 12 декабрь көнне 60 яшь тула. Абый, сине юбилеең белән котлыйбыз, сиңа исәнлек - саулык, озын гомер, тыныч тормыш телибез.

Кояш гомере бирсен сиңа ходай,
Шатлыкларың килсен өелеп.
Саулык - сәламәтлек юлдаш булсын,
Бәхетләргә яшә төренеп.

Иңизге теләкләр белән энегез Камил, киленегез Лилия.

Сәламәт булыгыз

БӨЕР СИНДРОМЫ БЕЛӘН ГЕММОРРАГИК БИЗГӘК - КУРКЫНЫЧ АВЫРУ

Табигатьтә кеше организмына зарарлы микробларын таратучы кыргый хайваннар яши. Аеруча урманда булганда алар кешегә йогарга мөмкин. Алар арасында табигатьтән чыккан каты вируслы авыру - бөер синдромы белән бизгәк авыруы (ГЛПС) иң куркынычы булып санала. Ул кан тамырларын һәм бигрәк тә бөерләрне зарарлый.Безнең республика шартларында бу авыруларны кызгылт, сирәк кенә очракларда кызыл тычканнар йоктыра. Яфраклы һәм катнаш урманнар аларның яраткан урыннары. Урманнарда кимерүчеләр күп яки азык кытлыгы булган очракларда алар өйләргә, сарайларга, умарталыкларга, фермаларга һәм дача корылмаларына таралалар.

ГЛПС вирусы әйләнә-тирә мөхиткә сидек, тәрәт,төкерек аша туфракка,яфраклар белән тәндәге яралар, киселгән урыннар аша, зарарланган ризык белән тукланудан йогарга мөмкин. Чир йокканнан соң авыру билгеләре чыкканчыга кадәр 2-3 атна үтә. Аның иң беренче билгесе - өшү, температура искәрмәстән башлана, баш авырта, буыннар, мускуллар авырта. Югары температура 3-5 көннән соң аз-азлап төшә башлый. Бу чорда бил, эч авырта башлый, кыскасы, бөерләрнең зарарлануы сизелә. Кайбер авыруларда кан китү күренешләре очрый, тәнгә тимгелләр чыга, кыска вакытка күз күрүе начарая, авыз кибә.

Кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итмәгән очракта ГЛПСның авыр, кеше гомере өчен куркыныч формалары барлыкка килергә мөмкин.

Әлеге куркыныч чирне кисәтү чаралары кешенең тычкансыман кимерүчеләр белән бәйләнешен булдырмау, ризыкны пычрануудан саклау, кимерүчеләрне торак йортларга кертмәүгә юнәлдерелгән.

Торак - көнкүреш биналарын сулатып җыеп торырга, азык-төлек продуктларын кимерүчеләр җитә алмаслык урыннарга куярга, аларны даими рәвештә юк итү чараларын күреп торырга кирәк. Бу очракта агуланган азык куллану файда бирә, аны санэпидкүзәтү үзәгендә алырга мөмкин (адрес: Школьная урамы,10нчы йорт). Агулы җимне кимерүчеләр йөри торган тишекләргә куярга һәм җим куйганнан соң тишекне цемент, алебастр белән томаларга кирәк.Күселәр юлына уртача 25 г., ә тычканныкына 3 г. агулы җим куялар. Күселәргә аны 3-4 көн рәттән 5-6 метр аша, ә тычканнарга 3-4 метр аша кую нәтиҗәле.

ГЛПС -йогышлы авыру, аңа каршы бөтенхалык бергә көрәшкәндә генә, аларны юк итү чараларын киң масса халык белән бергә күргәндә генә гемморрагик бизгәк авыруын кисәтү мөмкин булачак.

Н.ПРОКОПЬЕВА, санипедкүзәтү үзәгенең хезмәт гигиенасы буенча санитар табибы.

БЕЛДЕРҮЛӘР

Бер яки ике бүлмәле фатир сатып алам. Арадашчы телефоны: коммутатор аша 65 - 4 - 74.

***

Яшәп тору өчен фатир кирәк. Тел.: 5 - 23 - 41, 17 сәг.тән соң.

***

Яшәп тору өчен фатир кирәк. Адрес: 40 лет Октября ур., 1 - 13.

***

Югалган (коккер - спаниель) эт үзенең хуҗасын эзли. Тел.: 2 - 20 - 50.

***

«Татнефть», «Газпром» берләшмәләре акцияләрен сатып алабыз. Тел.: 5 - 37 - 69.

***

Яшәп тору өчен бер бүлмәле фатир (шикәр заводы һәм тимер юл бистәләреннән тәкъдим итмәскә). Тел.: 2 - 24 - 58.

***

Столярлык эшләре өчен ягыла торган бина арендага алам. Тел.: 5 - 16 - 25, Ирекка мөрәҗәгать итәргә.

***

Пыялалары белән тәрәзә рамы. Югары Норлат авылында Мифтахов Рифкатькә мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 31 - 23.

***

Запас частьләргә эшләп торган ВАЗ - 2106. Тел.: 2 - 32 - 32.

***

"ShARP" яңа магнитоласы (ике кассеталы, CD). Тел.: 5 - 19 - 49, кич белән.

***

1979 елгы "Москвич - 412", 4 млн. сум. Адрес: Козлов ур., 3 - 11.

БЕЛДЕРҮЛӘР

САТАБЫЗ

«Казан» пианиносы. Тел.: 2 - 21 - 93.

***

1995 нче елгы ВАЗ - 21061, 5ле тизлек күчерү тартмасы. Адрес: К.Маркс проспекты, 4 - 25.

***

1995 нче елның декабрендә чыккан газ җиһазларында эшли торган ВАЗ - 21061. Адрес: Карл Маркс ур., 2 - 48, тел.: 5 - 12 - 84.

***

1995 нче елгы ВАЗ - 21060, 32 мең км. юл үткән. Тел.: 5 - 37 - 69.

***

Линейная урамында 28 нче номерлы гараж. Тел.: 2 - 16 - 59.

***

Өч рожоклы «Угоп - 22» газ яккычлары. Мәрмәр плитәләр сатабыз, мәрмәр плитәдә портретлар ясыйбыз. Бәясе - килешү буенча. Адрес: Ленинградская ур., 14.

***

Туй күлмәге, кыймммәт түгел. Горький ур., 9, 15 сәг.тән соң.

***

Әйбәт хәлдәге ГАЗ - 2105. Тел.: 5 - 27 - 39.

***

Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2101. Тел.: 5 - 17 - 45, 25 - 80, 2 - 16 - 23.

***

7 мең км. юл үткән «Урал» мотоциклы һәм «Жигули» кузовы. Тел.: 5 - 18 - 35.

***

Ашыгыч рәвештә алып китү өчен тимер - бетон гараж. Адрес: Кооперативная ур., 4 - 19, тел: 2 - 12 - 18, сатулашырга мөмкин.

Бездә «STINOL»дан яңалык.

Шәһәр һәм район халкының күбесе «STINOL» суыткычларының ышанычлылыгы, матурлыгы һәм уңайлылыгына ышанырга өлгерделәр инде. Хәзер без бу файдалы техниканың 7 моделен тәкъдим итәбез. Алар арасында бәссез ике компрессорлы «STINOL - 102» дә бар. «Техника» кибетенең икенче катына килеп үзегезгә һәм якыннарыгызга Яңа ел бүләге ясагыз. Октябрь районы буенча илтеп бирү бушлай, 2 елга гарантия.

Һәрвакыттагыча, әйдәп баручы фирмаларда эшләнгән теле - видеоаппаратура, кухня комбайннары һәм тузан суырткычларның киң ассортименты бар. Бездән әйбер алып сез үз капиталыгызны дөрес урнаштыруга ирешерсез.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга,
рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтиш - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.